| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЬМЕТЬЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘЛМӘТ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» июль 2023 ел г. Альметьевск № 2398

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 24 декабрендәге 1913 номерлы "Торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йорт авария хәлендә , җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы «Бинаны торак бина, торак бина яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә тиешле дип тану, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына ярашлы рәвештә, Әлмәт прокурорының 2023 елның 14 июнендәге 02-08-01 номерлы протестын караганнан соң

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 24 декабрендәге 1913 номерлы "Торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йорт авария хәлендә, җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 23 мартындагы 639 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның 1 нче кушымтасы 3 нче бүлеге 3.5.7 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәге карарлар тора:

торак бинаны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану турында;

бинаның торак бинага куелган таләпләргә туры килүе һәм аның яшәү өчен яраклылыгы турында;

торак бинаның эксплуатация процессында югалтылган характеристикаларын китерү максатыннан бинаны капиталь ремонтлауга,

реконструкцияләүгә яки үзгәртеп планлаштыруга (кирәк булганда техник-икътисади нигезләмә белән) тиешле дип тану өчен нигезләрне ачыклау турында;

бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану өчен нигезләрне ачыклау турында;

торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану өчен нигезләр булмау турында;

күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм реконструкцияләнергә тиешле дип тану өчен нигезләрне ачыклау турында;

күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә тиешле дип тану өчен нигезләрне ачыклау турында;

күп фатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану өчен нигезләр булмау турында.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту район башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — А.М. Каюмов